# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 25 октябре № 2

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Гәр авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Гәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 2023 елда 600 (Алты йөз) сум күләмендә узара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне:

- Гәр авылында артык биек булып үскән карт агачларны кистерү;

- Гәр авылында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, төзекләндерү һәм карап тотуны (яктырткычлар, фотоэлементлар, исәпкә алу приборлары, идарә щиты, урам утлары өчен ЛЭП сатып алу һәм урнаштыру)

башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?”

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

соравы буенча 2022 елның 24 ноябрендә 12 сәгать 30 минутта уздырылган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 102 (Йөз ике) граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 53 кеше, бу 51,9 % тәшкил итә;

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 53 (Илле өч) кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 (ноль) катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Гәр авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2023 елда үзара салым акчасын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Гәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 600 (Алты йөз) сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Гәр авылында артык биек булып үскән карт агачларны кистерү;

- Гәр авылында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, төзекләндерү һәм карап тоту (яктырткычлар, фотоэлементлар, исәпкә алу приборлары, идарә щиты, урам утлары өчен ЛЭП сатып алу һәм урнаштыру).

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы: З. Р. Гарифуллина